БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» 10 2020 ел № 302

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2008 елның 23 маендагы карары белән расланган «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт өчен субсидияләр бирү турында» нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Муниципаль торак фондының күпфатирлы торак йортлары белән идарә итү өчен шартлар тудыру максатларында, Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2008 елның 23 маендагы карары белән расланган «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт өчен субсидияләр бирү турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 1.1. пунктында «Торак – коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» 185 – ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән» дигән сүзтезмәне төшереп калдырырга.

1.2. 2 бүлекнең 2.1.пунктындагы 2 абзацында «2008 елга Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү буенча адреслы республика программасы» дигән сүзтезмәне «2020, 2021 ,2022 елларга Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт региональ программасы»на алмаштырырга.

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 3 пунктны «3. Күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт буенча эшләрне башкару өчен подрядчы оешмаларны сайлап алу тәртибе» өстәргә:

«Подрядчы оешмалар Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары, муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан «Россия Федерациясе субъектлары территориясендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча эшләрне башкару һәм хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) подрядчы оешмаларны алдан сайлап алу комиссиясе эшчәнлеге тәртибе турындагы методик күрсәтмәләрне раслау хакында» 2016 елның 7 сентяберендәге 624/пр номерлы Татарстан Республикасы Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы белән расланган Тәртип нигезендә сайлап алына».

Субсидияләү субъекты түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:

- субсидия алучы чит ил юридик заты булмаска тиеш, шулай ук теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган дәүләтләрнең һәм территорияләрнең салым салуның ташламалы салым режимын бирүче һәм (яисә) әлеге юридик затка карата финанс операцияләрен (офшор зоналары) уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яисә территория торган чит ил юридик затының устав (җыелма) капиталында тулаем алганда катнашу өлеше 50 процентттан артып киткән Россия юридик заты булмаска тиеш;

- федераль бюджеттан алынган акчалар хисабына чит ил валютасын, югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлаштыру әйберләрен сатып алганда (китерткәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операциялардән, шулай ук әлеге акчаларны алу максатларына ирешүгә бәйле әлеге тәртиптә билгеләнгән башка операцияләрдән тыш, сатып алырга тиеш түгел;

- ул үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык хәлендә булмаска һәм аның хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләре булмаска тиеш.

1.4. Түбәндәге эчтәлекле 4 пунктны «4. Субсидияләрне куллануны контрольдә тоту һәм кире кайтару» өстәргә:

«4.1. Муниципаль финанс контроле органнары субсидия алучының субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерәләр.

4.2. Субсидия түбәндәге очракларда муниципаль берәмлек бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

4.2.1. субсидия алучы субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозган очракта;

Субсидияне күрсәтмә белән билгеләнгән вакытта кире кайтармаган очракта, аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозып тотылган субсидия суммасы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түләттерелергә тиеш.

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов